

Март - язнын беренче ае. Яз белән озакка талган йокысыннан кvкерәк тутырып сулыш алып кvзен ача табигать. Язгы табигать әйтерсен яна туган сабый! Кар астыннан жир кvренер-кvренмәс борын торткән яна vлән, яна чәчәк, яна ужым, яна боре... Язнын кояш нурларыннан, табигать тагын да балкый, нәфисләнә, уяна.
Кышнын салкыннарыннан сон һәрбер кеше язны сагынып котеп ала. Яз - ул табигатьнен кышкы йокыдан уяну вакыты. Зәнгәр кvктә язгы кояш елмая. Ой кыекларыннан тамчылар тама. Язгы жылыдан кар эреп, горләвекләр ага. Жылы яклардан туган якларына кошлар кайта.       Мордовия авылларында элек-электән кошларга оя ясап кую гадәте яши. Бигърәк сыерчык оялары. Мәктәп укучылары, хәтта укучы булмасалар да сыерчыклар килер алдыннан әзерләп куйган ояларны агачларга эләләр. Республикабыз буенча ел саен кош оялары ясап кую акциясе уза. Табигатьне саклауга юнәлдерелгән әлеге акциянен vзәк вакыйгасы – балалар арасында кошлар очен жимлекләр һәм сыерчык оялары ясау. Быел да бара ул. Экология елы игълан ителгәч, кошларга оялар кую гына тvгел, бу теманы ачыклаган торле конкурслар да игълан ителде.
Сагындырып, ялындырып, табигатькә яз килә. Язгы жылы жил агачтагы яшь бореләрне уята. Тиздән алар шаулап я



фрак ярырлар. Без куйган ояда кошларнын чебиләре черкелдәшә башлар. Кешеләр язгы эшләргә керешерләр. Кырларда язгы кыр эшләре башланыр. Кырларга ашлама кертv очен торле ашлама белән тутырылган йок машиналары шәһәрдән авылларга таба юнәлгәннәренә тап буласын. Урамда балаларнын шат тавышлары ишетелә, чонки тиздән, 27нче мартта язгы каникуллар башланачак.
Туган жиребезгә яз килә. Яз житкәч, кvчмә кошлар vзләренен туган якларына кайталар, дидек. Беренче булып кара каргалар очып килә, алардан сон сыерчыклар кvренә башлый. Сонрак тургайлар, кvкеләр, сандугачлар, карлыгачлар очып кайталар. Кошлар килгәч, табигать тагын да матурлана. Сыерчыклар килергә вакыт якынлашкач, килмәделәрме диеп кvзләп йори идек, бигъряк балачакта. Бездә шундый сынамыш та бар иде: кайткан сыерчыкнын беренче буларак берничәсен кvрсән – ялгыз булмыйсын, дип әйтә иделәр. Гаиләлеләр - гаиләсе ишәюгә, яшvсмерләр - берәр дус артырмы, юкмы икәненә юрый идек. Бvген шул гадәтләр яшиме икән, анысы кызыклы.
- Ин матур сыерчык оясы дигән конкурслары мәктәпләрдә vткәрелә торган Кошлар коненә багышлап Дубенка районы Ломат, аннары Кочкурово мәктәбендә биология укытучысы белән бергәләп vткәрә идек, - дип сойләде Альфия Кетдюс кызы Узбякова. Быел да укучылар белән бергә vткәрергә жыенабыз. Сыерчык оялары да авылыбызда кvп урнаштырылган, искеләрен яналарына да алмаштырып эләләр. Минем армиядә хезмәт итvче улым Азат та vткән елны сыерчык оясы ясап элде. Сыерчыгыбыз быел да оябызны vз итәр дип уйлыйм.
Укучыларга кошлар коненә vзләренен гәvдәләре кадәр авырлыкта божәкләрне ашап юк итvләре, vсемлекләрне торле божәкләрдән саклап калулары, табигатькә бик кvп файда китерvләре турында кvп сойлибез. Һәм без кошларны сакларга һәм аларга ярдәм итәргә тиешлегебезне дә оныттырмыйбыз, ояларны да вакытында ясап куябыз. Алар безнен дусларыбыз булып яшәсеннәр, - ди Альфия Кетдюсовна.

**Наилә Насырова**